**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

29.08.2022

КАРАР

№ 944

2021 елның 21 сентябрендәге 991 номерлы җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32.1 статьяларына 2022 елның 25 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә:

- 2.5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9 пунктчаны өстәргә:

«Җир кишәрлеген бирү турында гариза бирелгән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүне раслый торган документ, әгәр ата-ананың яисә бердәнбер ата-ана Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлеген бирү турында гариза бирелгән көнгә кадәрге биш ел дәвамында яшәсә, җир кишәрлеген бирү хакындагы гариза биргән көнгә кадәрге биш ел дәвамында мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын җир кишәрлеген бирү хакындагы гариза биргән көнгә кадәрге биш ел дәвамында билгеләү турында суд карары (мөрәҗәгать итүче паспортында җир кишәрлеген бирү турында гариза бирелгән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча аны теркәү турында тамга булмаган очракта)».

- 2.5.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ буларак исәптә торуын раслый торган документ, әгәр мөрәҗәгать итүче аны үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә соратып алына.»

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесенә йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин